Хокукый акт проекты буенча гавами тыңлаулар башлану турында

# ХӘБӘР ИТҮ

Татарстан Республикасы, Кайбыч муниципаль районы, Олы Кайбыч авыл җирлеге, Северная ур. адресы буенча урнашкан 16:21:010107:400 кадастр номерлы җир кишәрлеген файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында боерык проекты буенча гавами тыңлаулар башлануы турында хәбәр итәбез.

Проектка мәгълүмати материаллар исемлеге:

1. Җир кишәрлеге буенча гавами кадастр картасыннан мәгълүмат;
2. Олы Кайбыч авыл җирлегенең шәһәр төзелешен зоналаштыру картасы;
3. Олы Кайбыч авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелешләр кагыйдәләреннән шәһәр төзелеше регламентлары турында мәгълүмат.

Проект буенча гавами тыңлаулар үткәрү тәртибе һәм сроклары:

1. Гавами тыңлауларга чыгарылган мәсьәләнең асылы буенча чыгышлар.
2. Гавами тыңлауларда катнашучыларның сорауларын һәм тәкъдимнәрен карау.

Гавами тыңлауларда катнашучылар чыгыш ясаучыларга барлык чыгышлар тәмамланганнан соң сораулар бирергә хокуклы. Сораулар һәм тәкъдимнәр язма рәвештә бирелә. Гавами тыңлаулар үткәрү срогы: 2025 елның 18 декабреннән 2025 елның 26 декабренә кадәр.

Гавами тыңлауларда катнашучылар даирәсе: Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты, җир кишәрлеге урнашкан территориаль зона чикләрендә даими яшәүче гражданнар, шушы территориаль зона чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләренең һәм (яисә) аларда урнашкан капиталь төзелеш объектларының хокук ияләре, шундый җир кишәрлекләрендә урнашкан капиталь төзелеш объектының бер өлеше булган биналарның хокук ияләре.

Ачык тыңлауларда каралырга тиешле проект экспозициясен (экспозицияләрен) ачу урыны һәм датасы: Кайбыч районы, Олы Кайбыч ав., Кояшлы бульвар, 7 й., 2 нче кат, 209 нчы кабинет адресы буенча урнашкан Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге.

Экспозициягә (экспозицияләргә) бару мөмкинлеге булган көннәр һәм сәгатьләр турында мәгълүмат: 2025 елның 25 декабрендә 8.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр, 2025 елның 26 декабрендә 8.00 сәгатьтән 10.00 сәгатькә кадәр.

Проектка кагылышлы тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне гавами тыңлауларда катнашучылар тарафыннан кертү тәртибе, сроклары һәм рәвеше:

- проект буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр 2025 елның 18 декабреннән 2025 елның 25 декабренә кадәр 8.00 дән 17.00 гә кадәр язма рәвештә Кайбыч районы, Олы Кайбыч ав., Кояшлы бульвар, 7 й., 2 кат, 209 нчы кабинет адресы буенча урнашкан Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлегендә кабул ителә.

Ачык тыңлауларда каралырга тиешле проект һәм аңа мәгълүмати материаллар урнаштырылган рәсми сайт турында мәгълүмат: Кайбыч муниципаль районының рәсми сайты «Сайтка килүчеләр өчен файдалы мәгълүмат» бүлегендә (http://kaybici.tatarstan.ru).

Әлеге хәбәрне Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында «Сайтка керүчеләр өчен файдалы мәгълүмат» бүлегендә (http://kaybici.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (https://pravo.tatarstan.ru/) һәм Татарстан Республикасы, Кайбыч районы, Олы Кайбыч ав., Кояшлы бульвар, 7 й. адресы буенча урнашкан Иҗтимагый үзәк мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Башкарма комитеты Җитәкчесе А.Н. Макаров